# Казан федераль университеты

DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ
абитуриентлар өчен
махсус чыгарылыш

№ 19 (112)
20 июнь 2014 ел




www.kpfu.ru
чыгарылышның тулы мультимедиа-version
UNIVERSMOTRI.RU рубрика «абитуриенту»

## *Хөрмәтле чыгарылыш сыйныф укучылары!*

Сезнең өчен күңелле һәм дулкынландыргыч мизгелләр килеп җитә. Бик тиздән мәктәп тормышы артта калачак, әмма сез инде хәзер: «Алга таба кая барырга?» – дигән сорауга җавап эзлисез. Шушы авыр чорда дөрес юл сайларга кирәк. Ул киләчәктә, һичшиксез, җәмгыять өчен файдалы белем алырлык булырга тиеш.

Быел 210 еллыгын билгеләячәк Казан университеты һәрвакыт сәләтле, актив, ныклы белем алырга теләүче яшьләрне җәлеп итте. Бүген, уку йортыбыз федераль университет статусын алгач, икътисадның реаль секторында кирәкле һәм әһәмиятле булган белем һәм күнекмәләр бирү мөмкинлегебез тагын да артты.

Әгәр синең талантың, һөнәри һәм тормыш амбицияләрең ташып тора икән, барлык сәләтләреңне ачасың, үзеңне көчле шәхес итеп тәрбиялисең һәм танытасың килә икән, Казан федераль университеты нәкъ менә сине көтә! Монда алган белемнәрегезнең лаеклы киләчәккә уңышлы адым булуын телим!

**Илшат ГАФУРОВ,**
**КФУ ректоры**



## Казан Федераль Университеты – Камил Фикерле Укымышлы булу сере!

**ӘЙЕ, БЕЗ БАРЫ ТИК АКЫЛЛЫ ҺӘМ ТАЛАНТЛЫЛАРНЫ ГЫНА УКЫРГА КАБУЛ ИТӘБЕЗ!**
**КФУ** – Россиядәге дөньяның ТОП-100 университетлары исемлегенә эләгергә дәгъва кылган иң яхшы югары уку йортларының берсе.

**ӘЙЕ, БЕЗДӘ УКУ– ЗУР АБРУЙ!**
**КФУ** – фән һәм мәгариф эшчәнлегенең иң югары дәрәҗәсе!

**ӘЙЕ, БЕЗДӘ КОНКУРЕНЦИЯ ЗУР!**
**КФУ** – алдынгы чит ил университетларында стажировка узу мөмкинлеге, «икеләтә диплом» программалары, стипендияләр һәм грантлар.

**ӘЙЕ, БЕЗДӘ УКЫЙЛАР ДА, АКЧА ДА ЭШЛИЛӘР!**
**КФУ** – студент вакытта ук эшмәкәрлеккә өйрәнү

**ӘЙЕ, БЕЗ ЧЫГАРЫЛЫШ КУРС СТУДЕНТЛАРЫНА ЫШАНАБЫЗ!**
**КФУ** – гарантияле эшкә урнашу.

**ӘЙЕ, УНИВЕРСИТЕТ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ШӘҺӘРДӘ УРНАШКАН!**
**КФУ** – ул Казан, Россиянең иң яхшы шәһәрләренең берсе, Татарстан һәм Универсиада 2013 башкаласы!

**ӘЙЕ, БЕЗ АКТИВ СТУДЕНТЛАРНЫ ЯРАТАБЫЗ!**
**КФУ** – күңелле студент тормышы: фестивальләр, турнирлар, концертлар

**ӘЙЕ, БЕЗНЕҢ СТУДЕНТЛАР УҢАЙЛЫ ШАРТЛАРДА ЯШИ!**
**КФУ** – Төрле төбәкләрдән килгән студентлар өчен иң яхшы студентлар кампусы.
Иң яхшы булуыңны исбатла – **КФУ**га укырга кер!

## Укырга ничек керәбез?

### Кабул итү комиссиясенә документларны бернichә төрле юл белән тапшырырга мөмкин:

- Шәхсән үзең КФУның кабул итү комиссиясенә килеп (Казан, Кремль урамы, 35 йорт, II корпус, 114, 115, 116 бүлмәләр);
- ☎8(843) 292-73-40, 233-70-76) гариза яза аласың http://kpfu.ru/main_page?p_sub=6253;
- 25 июльдән дә калмыйча, кирәкле документларның күчермәләрен почта аша юлларга була. Адрес: 420008, Казан, Кремль урамы, 18 йорт, КФУның кабул итү комиссиясе;
- гаризаларны 20 июньнән 25 июльгә кадәр abiturient.kpfu.ru электрон сайты аша да җибәрергә мөмкин.
- БДИдан тыш, университетта эчке имтихан тотучылар документларын 25 июльгә кадәр тапшырырга тиеш.
- нинди дә булса ташламаларга ия булучылар шәхсән үзләре килергә тиеш!



**Шуны исеңдә тот:**
абитуриент һәр вузда өчтән дә артык юнәлеш буенча конкурста катнаша алмый. Ә вузлар саны үзгәрмәдә. Алар һаман да бишәү. Гариза биргәндә филиал хокукындагы институтлар аерым вуз сыйфатында санала.

### Сайтлар юл күрсәтә!

Сезгә һәр институт-факультетның сайт адресын тәкъдим итәбез. Тулырак мәгълүматны һәм яңалыкларны сез биредә таба аласыз!

- Фундаменталь медицина һәм биология институты kpfu.ru/main_page?p_sub=213
- Экология һәм география институты kpfu.ru/main_page?p_sub=214
- Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты kpfu.ru/main_page?p_sub=215
- Инженерия институты http://kpfu.ru/engineer
- Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты kpfu.ru/main_page?p_sub=216
- Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты kpfu.ru/main_page?p_sub=217
- Физика институты kpfu.ru/main_page?p_sub=218
- А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты kpfu.ru/main_page?p_sub=219
- Юридик факультет kpfu.ru/main_page?p_sub=220
- Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты kpfu.ru/main_page?p_sub=221
- ИТИС Югары мәктәбе http://kpfu.ru/itis
- Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты kpfu.ru/main_page?p_sub=222
- Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты kpfu.ru/main_page?p_sub=224
- Икътисад һәм финанс институты kpfu.ru/main_page?p_sub=5102
- Педагогика һәм психология институты kpfu.ru/main_page?p_sub=88
- Фәлсәфә факультеты kpfu.ru/main_page?p_sub=89
- Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты kpfu.ru/main_page?p_sub=91
- Идарә һәм территориаль үсеш институты kpfu.ru/main_page?p_sub=86
- Яр Чаллы институты kpfu.ru/main_page?p_sub=6206
- Алабуга институты kpfu.ru/main_page?p_sub=6207
- Чистай филиалы filinch.ru/

## Үсеш юлында – 8 өстенлекле юнәлеш:

- яңа материаллар һәм нанотехнологияләр;
- мәгълүмати-коммуникацион технологияләр;
- биология, медицина һәм тере системалар технологиясе;
- табигатьтән рациональ файдалану;
- күп дәрәҗәле мәгариф системалары, гуманитар һәм педагогик технологияләр;
- мәдәниятара коммуникацияләр, Көнчыгышны өйрәнү, төбәк һәм халыкара мөнәсәбәтләр;
- төбәкнең социаль-икътисади үсеше, алдан күрү һәм идарә итү технологияләре;
- кара алтын-газ технологияләре.

# КФУның белем бирү комплекслары

## ФИЗИКА-МАТЕМАТИКА ЮНӘЛЕШЕ

- Физика институты
- Н.И.Лобачевский ис. Математика һәм механика институты
- Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты
- Мәгълүмати Технологияләр һәм Системалар югары мәктәбе (ИТИС)
- IT лицей-интернат
- Инженерия институты

## ТӨГӘЛ ФӘННӘР ЮНӘЛЕШЕ

- Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты
- А.М.Бутлеров ис. Химия институты
- Фундаменталь медицина һәм биология институты
- Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты
- Экология һәм география институты

## СОЦИАЛЬ-ГУМАНИТАР ҺӘМ ИКЪТИСАДИ ЮНӘЛЕШ

- Филология һәм мәдәниятара баглагышлар институты
- Идарә һәм территориаль үсеш институты
- Икътисад һәм финанс институты
- Дәүләт һәм муниципаль идарә итү югары мәктәбе
- Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты
- Психология һәм мәгариф институты
- Телләр институты
- Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты
- Юридик факультет
- Фәлсәфә факультеты

## ФИЛИАЛЛАР:

- Яр Чаллы институты
- Алабуга институты
- Чистай филиалы



# Мең яшьлек Казан, Мең яшәр Казан!

(Р.Әхмәтҗан)

**Казан – Идел буендагы иң борынгы тарихи шәһәрләрнең берсе булып санала. 2005 елда үзенең 1000 еллыгын билгеләгән Казан бүген чын мәгънәсендә илебезнең икътисади, фәнни һәм мәдәни үзәкләре рәтендә исәпләнә.**

Моның чыннан да шулай икәнлеген шәһәр 2013 елгы Универсиаданы үзендә кабул итеп исбатлады. Төрле илләрдән килгән спортчы-студентларны, туристларны Казан үзенең тарихилыгы, матурлыгы, байлыгы белән сокландырды. Хәзерге көндә мәдәният, дин һәм тел төрлелеге шартларында шәһәрдә 100дән артык милләт вәкиле, барлыгы 1,2 миллион кеше яши. Бу уңайдан, Казанны Россиянең иң «интернациональ» шәһәре дип билгеләп үтәргә кирәк.

Бүген Казан – бөтен уңайлыклары булган заманча шәһәр. Ул үзенең тарихи истәлекле урыннары, архитектурасы белән сокландыра. Казанның иң танылган мәдәни һәйкәле – ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы корылмасы булган Казан Кремле. Казанлылар һәм туристлар өчен тарихи комплекс һәр көн ачык. Биредә Сөембикә манарасы, Спас манарасы, Благовещение соборы, дөньядагы иң зур мәчетләрнең берсе – Кол Шәриф кебек мәдәни-архитектура һәйкәлләрен күреп була.

Казанда транспорт системасы зур үсеш алган. Хәзерге көндә күптармаклы автобус, трамвай, троллейбус маршрутлары челтәре булдырылган. 2005 елда Татарстан башкаласында метрополитен да эшли башлады. 2013 елның 9 маенда, XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада башлану алдыннан, «Яшьлек», «Төньяк вокзал» һәм «Авиатөзелеш» дип аталган яңа метро станцияләре ачылды. Киләчәктә метро станцияләрен тагын да җәелдерү, тармакландыру күздә тотыла.

Казан актив мәдәни тормыш белән яши. Монда 30дан артык музей, берничә дистә китапханә, 9 театр, күп санлы парклар, күңел ачу һәм ял итү урыннары бар. Казанда И.Ф.Шаляпин исемендәге Халыкара опера фестивале, Р.Х.Нуриев исемендәге балет фестивале, С.В.Рахманинов исемендәге классик музыка фестивале, «Казан көзе» ачык һавадагы опера фестивале, «Конкордия» заманча музыка фестивале, «Аксёнов-фест» әдәбият фестивале, Казан мөселман киносы фестивале үтә. «La Primavera» Казан камера оркестрының даны исә чит илләргә дә таралган. Шулай ук шәһәрдә татар һәм рус халыкларының милли бәйрәмнәре үткәрелә.

Бүген шәһәрнең инфраструктурасы танымаслык булып үзгәрде. Яңа йортлар, социаль корылмалар, спорт корылмалары төзелә. Шәһәрнең икътисады инновацион юл буенча үсеш ала. Казанда Европадагы иң эре технопаркларның берсе – «Идея» технопаркы һәм IT-парк эшләп килә.

Меңьеллык тарихка ия булган Казанны яшьләр шәһәре, студентлар каласы, дип атыйлар. Татарстан башкаласында 67 илдән 200 мең студент белем ала. Россиянең иң зур югары уку йортларының берсе булган Казан федераль университеты – Казанның горурлыгы, Татарстанның горурлыгы!

Казан университеты – илебезнең иң борынгы университетлары рәтендә. Аңа 1804 елда император Александр I указы белән нигез салына. Казан университеты, аның факультетлары Идел буендагы уннан артык югары уку йортының нигезе, башлангычы булып тора. Нәкъ менә Казан университетында Н.И.Лобачевский Евклидча булмаган геометрияне яза, А.М. Бутлеров – органик кушылмалар теориясен, ә К.К.Клаус рутений химик элементын ача, Е.К.Завойский – электрон парамагнит резонанс, ә С.А.Альтшулер акустик парамагнит резонанс турында фәнни хезмәтен яза.



Бүген Казан университеты Times Higher Education 600 Best World Universities версиясе буенча дөньяның иң яхшы университетлары рәтенә кертелгән. Уку йорты барлыгы 30дан артык чит ил университетлары белән хезмәттәшлек итә, төрле халыкара программаларда катнаша, Халыкара университетлар ассоциациясе әгъзасы булып тора.

2009 елның октябреннән университет федераль статуска ия. Бу вакыйга Казан университеты тарихының 205 еллык юбилееның мантыйкый дәвамына әверелә. Бүген КФУ классик университет үрнәге – ныклы, нигезле белем һәм бертуктаусыз үсеш чыганагы.

Хәзерге көндә уку йортында фундаменталь медицина һәм фармацевтика, инженерия юнәлеше, Идел буе халыкларының мәдәнияте һәм телләре, логистика, урбанистика, исламны өйрәнү, фәнни-техник һәм социаль-икътисади юнәлешләрне үстерүгә аеруча күп көч куела.

КФУның 300 кафедрасында 409 фән докторы һәм 1471 фән кандидаты дәресләр алып бара. Алар арасында Россиядә һәм Европада зур дәрәҗәләргә ирешкән галимнәр дә бар. Өстәвенә КФУ даими рәвештә Страсбург һәм Сорбонна, Гиссен, Истамбул, Токио университетларыннан да лекторлар чакыра. Университет Татарстанның барлык эре предприятиеләре һәм кайбер Европа, Азия илләренең җитештерү һәм инжиниринг компанияләре белән хезмәттәшлек программасына да ия.

Биредә студентлар өчен бик зур мөмкинлекләр ачыла. Алар үзләрен фәнни яктан да, иҗади яктан да, спорт буенча да үстерә һәм зур уңышларга ирешә ала. Уку белән беррәттән, җырлап-биеп, уйнап-көлеп яши биредә студентлар. Студентлар тырышлыгы, укытучы-профессорлар коллективы ярдәме белән 210 еллыгын каршы ала торган бөек университет зур җиңүгә – ТРның ел саен бирелә торган «Ел студенты – 2013» премиясендә «Ел вузы» номинациясендә гран-прига лаек булды.

КФУ зур үрләр яулавын дәвам итә. Аның ил күләмендә генә түгел, дөньяда алдынгы уку йортларының беренче рәтләрендә булачагына шик юк.

**Синең ана телебезнең бөтен нечкәлекләрен беләсең, моңлы итеп җырларга, дәртле итеп биергә өйрәнәсең, рәсем ясау серләренә төшенәсең, чит телдә камил аралашасың, заманча технологияләр белән дә дуслашасың киләме? Шуларга өстәп, син әле үзең белгәннәрне башкаларга да өйрәтергә телисеңме? Алайса, туп-туры Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтына кил! Биредә сине зур тормышка ышанычлы итеп аяк басарга әзерләячәкләр!**

# Син дә безнең белән бул!


Бүгенге көндә институт составында **өч бүлек – Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар, Л.Н.Толстой исемендәге рус һәм чит ил филологиясе бүлекләре, С.Сәйдәшев исемендәге Югары сәнгать мәктәбе** бар. Бу институт КФУның иң эре институтларының берсе булып тора. Тагын шунысы куанычлы: Россия Президенты В.Путин **Россия Президенты каршында рус теле советы** булдыру турында карарга кул куйды. Совет составына институт директоры, профессор **Рәдиф Рифкать улы Җамалетдинов** та кертелде.

Татар халкы борынгыдан ук мәдәниятка, телгә, сәнгатькә гашыйк милләт булган. Бүген дә горур итеп, ныклы адымнар белән алга атлый. Үткән белән бүгенгене тоташтыру, милләтебезнең бөтен хәзинәсен саклап, киләчәккә тапшыру өчен яшь буын җаваплы. Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге башкаларыннан миллилеге, тыйнаклыгы белән аерылып тора. Студентларны күпкырлы шәхес итеп тәрбияләүгә укытучылар бөтен көчләрен куя. Алар сезгә төпле белем һәм ныклы тәрбия бирүдән тыш, якын кешеләрегезгә, киңәшчеләрегезгә әверелер.

Л.Н.Толстой исемендәге рус һәм чит ил филологиясе бүлегенең төрле чор традицияләрен берләштергән зур тарихы бар. Бүлекнең алдынгы юнәлешләренең берсе булып, заманча укыту технологияләре ярдәмендә чит телләр буенча тәҗрибәле белгечләр әзерләү тора. Биредә 4 чит тел - инглиз, испан, француз һәм немец телләре укытыла. Бүлек базасында Кембридж университетының безнең республикада бердәнбер имтихан кабул итү үзәге бар. Монда инглиз һәм француз телләре буенча халыкара сертификация проекты тормышка ашырыла.

С.Сәйдәшев исемендәге Югары сәнгать мәктәбенең укыту һәм фәнни-иҗади диапазоны бик киң. Биредә студентларның **фәнни түгәрәкләре**, **иҗади-эксперименталь лабораторияләр**, **компьютер технологияләре үзәге**, **«Tatarstyle» кием дизайн-студиясе**, **«АРТиФАКТ» факультет гәҗите**, **музыкаль-педагогик театрлар** эшләп килә. Һәрдаим **«Ренессанс»** матур әдәбият салоны утырышлары уза. Ул шулай ук **халык уен кораллары оркестры**, **скрипкачылар ансамбле**, **«Сәлам»**, **«Зарница»** фольклор ансамбльләре, **«Казаным»** халык бию ансамбле белән дан тота. Студентлар белем алу дәверендә заман таләпләренә туры килә торган, бүгенге көндә күп кенә рәссамнар, дизайнерлар, рекламачылар, полиграфистлар куллана торган барлык график һәм музыкаль-компьютер программаларын да үзләштерәләр, инглиз телен өйрәнәләр, төрле интерьер дизайннары, шәһәр архитектурасы, ландшафт объектлары проектларын төзиләр; заманча тавыш һәм ут эффектларын кулланып, спектакльләр, хореографик номерлар куялар. Кайбер педагогик яисә иҗади оешмалар үзләрен яхшы яктан күрсәтергә өлгергән студентларның диплом алганнарын эшләкле тәкъдим белән көтеп торалар.









**Ни генә әйтсәгез дә, студент еллары – иң күңелле һәм истә кала торган вакыт. Моңа, әлбәттә, мин үзем студент булгач инандым. Аеруча КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында белем алучы студентларның тормышы кызыгырлык.**





Укудан тыш, яшьләр төрле күңелле чараларда катнашалар: иҗат белән шөгыльләнүчеләр **«Әллүки»** берләшмәсенә йөри, **«Илһамлы каләм»** конкурсында, **«Шигъри Сабантуй»**да катнаша, **«Мизгел»** яшьләр театрында уйный. Җырга мәхәббәте булганнар **«Ал Зәйнәбем»** һәм Фатыйма Әхмәдиева җитәкчелегендәге вокаль ансамбльгә йөриләр. Шаулап-гөрләп, **«Яшьлек»** бию ансамбле эшләп килә. Ә күптән түгел Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегендә өр-яңа **«Tatar team»** КВН командасы оешты. Яшь команда сәхнәгә чыгарга да өлгермәде, бөтен татар КВН лигасын шаккаттырды. Нәтиҗәләр дә таң калырлык. Өч ай эчендә «Tatar team» өч җиңүгә иреште. Яр Чаллыда узган татар лигасының ярымфиналында, «Сәләт» лигасында беренчелекне бирмәделәр. «Афәрин»нән башка сүз юк!

Институтыбызның беренче татар КВН командасы студентлар теләге белән барлыкка килде. Бу төркемдә барлыгы 10 катнашучы, барысы да шаян, иҗади, сәләтле. Моңдый яшьләребез булганда, һичшиксез, татар юморы алга китәчәк.

Төркемдәшем **Ләйсән Шәрәфетдинованы** ФһМБ институтында гына түгел, хәтта Университет күләмендә дә белмәгән кеше юктыр. «Джордж Байрон» командасының «Иң яхшы артист»ы исеменә лаек булган кызыбыз «Tatar team»га да уйный. Ләйсән үзе: «Мин бит татар кызы, татар филологиясендә укыйм! Татар сәнгатен, татар юморын без үстермәсәк, бу эшкә кем алыныр?» – дип аңлатты.

Кадерле абитуриент! Әгәр безнең уку йортын сайлап, югары дәрәҗәле филолог булырга телсәң, сине дә шундый күңелле студент еллары көтә. Безнең институтта белем алу, фәнни ачышларга ирешү, иҗади талантыңны ачу һәм үстерү өчен бар мөмкинлекләр дә тудырылган. Бары тик синең актив, креатив, тырыш булуың гына кирәк.

**Айзилә Батрханова,**
ФһМБ институтының 1 курс студенты

# Белем белемгә тартыр!

**Казан халыкара лингвистик үзәге мәктәп укучылары, студентлар, укытучылар һәм төрле яшьтәге, төрле өлкәдә хезмәт куючы кешеләр белән эшли.**







Гомумән, ул биш проектны гамәлгә ашыра. «Центр притяжения» проекты чит илләр вәкилләрен рус һәм милли телләр белән кызыксындыруны, аларны өйрәнүгә чит ил студентларын җәлеп итү максатын тормышка ашыра. Күпләр инде яратып өлгергән «Ана теле» онлайн-мәктәбе дә бу проектка карый. Рус теленә бәйле онлайн мәктәп булдыру ниятләре дә бар икән. Алга таба чит илләрдә дә татар теле үзәге булдыру планлаштырыла. Бу зур масштаблы проект Каюм Насыйри исемен йөртер дип фаразлана.

«Гражданин мира» проекты конкурентлыкка сәләтле белгечләр әзерләүгә өөз тота. Монда сүз программаларны интернациональләштерү турында бара, ягъни, КФУның башка уку йортлары белән төзелгән килешүләре нигезендә, уртак белем бирү модульләре булдырыла. Нәтиҗәдә, ике уку йортының студентлары бер дистанцион мәйданда берләшә.

Университетка сыйфатлы белемгә ия булган абитуриентлар кирәк. Шул нисбәттән, мәктәп укучылары белән эшли торган «Поколение NEXT» проекты гамәлгә кертелә. Биредә шәкертләр үзләрен кызыксындырган телләр буенча Бердәм Дәүләт имтиханнарына әзерләнәләр. Монда, инглиз теле белән беррәттән, рус теле һәм әдәбияты, татар теле һәм әдәбиятыннан әзерлек дәресләре алып барыла.

Каршылыклы заманда яшәгәнлектән, без барыбыз да конкурентлыкка сәләтле булырга тырышабыз. Ә тел – аның бер өлеше. Шуна күрә хәзерге вакытта берничә тел белү – ул зарури әйбер. «Преподаватель 2.0» проекты укытучыларның белемен үстерү белән шөгыльләнә. Фәнни-педагогик кадрларның тел компетенцияләрен арттыру максатын күздә тоткан бу курсларда Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов та тыңлаучылар рәтендә.

«Ноу хау» исемле проект дәүләти һәм муниципаль хезмәткәрләр, пенсионерлар, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең һәм башка категория вәкилләренең филология буенча компетенцияләрен арттыру юнәлешендә эшли. Инвалидлар өчен махсус җайланмалар да булдырылган.

Рус, татар, инглиз, алман, француз, испан һ.б. телләрне яхшырак, төптәнрәк беләсегез килсә, Казан халыкара лингвистик үзәгенә рәхим итегез! Һәр илнең ачкычы – тел, телен белгән ил ачар. Бик күп илләрне ачарга язсын сезгә!

# Татар халкының яңа бренды!




**Уку йорты зур юбилеен – 210 еллыгын каршы алганда, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты базасында «Tatarica» халыкара журналы чыга башлады.**

Аның баш мөхәррире – әлеге институтның директоры, филология фәннәре докторы, профессор Рәдиф Җамалетдинов.

Дөнья стандартларына туры килгән басма илебез һәм чит ил белгечләренең татар халкы өйрәнү өлкәсендәге аеруча мөһим булган нәтиҗәләре, ачышлары белән таныштырып барачак. Журналда татар халкының теле, әдәбияты, тарихы, фольклоры, фәлсәфи һәм дини фикерләре, мәгарифе, мәдәнияте һәм сәнгате турындагы материаллар урын алачак. Шулай ук цивилизация тарихына зур өлеш керткән һәм хәзер дә заман таләпләренә лаеклы мөхиттә яши торган татар халкы турындагы фәнни база тулыландырылачак һәм янартылачак.

Журнал 7 бүлектән тора: «Тел», «Әдәбият», «Тарих һәм җәмгыять», «Мәдәният, шәхес һәм мәгариф», «Personalia», «Рецензияләр һәм күзәтү», «Төрки дөнья хроникасы». Анда шушы өлкәләрдәге тикшеренүләргә бәйле монографияләрнең рецензияләре һәм күзәтүләр, диссертацион эзләнүләр, татарика мәсьәләләрен өйрәнүгә зур өлеш керткән белгечләр төрки дөньяның фәнни вакыйгалары хакында мәгълүматлар, шулай ук татар галимнәре турында үзенчәлекле мәкаләләр бастырылачак.

«Tatarica»ның төп теле – инглиз теле. Шулай да барлык материалларның татар һәм рус телендәге аннотацияләре булачак. Татар һәм рус телендә язылган мәкаләләр инглиз телендә дә тәкъдим ителә.




# Онлайн-мәктәптә – онлайн-укытучылар!

**Татар телен өйрәнү буенча күпләргә таныш булган «Ана теле» онлайн-мәктәбе татар телен һәр теләүчегә бушлай өйрәнергә мөмкинлек бирә.**

Онлайн-мәктәп Россиядә, Татарстанда яшәүчеләр өчен генә түгел, ә чит ил вәкилләре өчен дә хезмәт куя. Анда җир шарының теләсә кайсы почмагыннан, тәүлекнең төрле вакытында белем алып була. Грамматика, лексика, фонетика һәм сөйләү практикасын өйрәнү өчен, уку материаллары аудиоролик һәм видеофильмнардан төзелгән дәресләрдән гыйбарәт.

«Мәктәп»тә укытучылар белән дистанцион аралашу мөмкинлеге булдырылды. Мондый дәресләр КФУның Казан халыкара лингвистик үзәге каршындагы «Ана теле» үзәге базасында тәкъдим ителә. Аларны Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты укытучылары алып бара. «Бер дәрескә 6 укучы керү мөмкинлеге бар. Бер үк вакытта, әйтик, Алабуга, Казан, Чаллы шәһәрләре, чит ил вәкилләре дә шөгыльләнә ала. Методистлар расписаниене алдан төзи. Кулланучы исә «Уку бүлмәсе» дигән төймәгә басып, кайсы көнне һәм сәгать ничәдә кайсы бүлек буенча дәресләр булачагын белә ала. Дәрес башлангач, ун минут эчендә керү мөмкинлеге каралган. Дәрес 45 минут бара, укучылар 8-9 слайдның эчтәлеге буенча укытучы белән сөйләшәләр, үзара аралашалар. Дәрес беткәч, укытучы алар белән саубуллаша, ә кулланучылар 15 минут дәвамында үзара фикер алыша ала әле», – ди «Ана теле» үзәге җитәкчесе Кадрия Фәтхуллова. Кулланучы үзенең телне үзләштерү дәрәҗәсен «Минем прогресс» төймәсенә басып тикшерә ала.

**Син Казан федераль университетына укырга керергә яисә аның эшчәнлеге белән һәрдаим кызыксынып торырга телисеңме? Алайса, түбәндәге мәгълүмат нәкъ синең өчен!**

# Белмәгәннең башы авырта!

## Университетның рәсми сайты

Әгәр сезгә тиз арада гына университет белән бәйле телефон номеры я булмаса e-mail кирәк, яисә бездә үтәчәк вакыйгалар белән кызыксынасыз икән, Интернеттан **kpfu.ru** адресын җыегыз. Биредә сез иң соңгы һәм дөрес яңалыклар, хәбәрләр белән танышырсыз. Казан федераль университеты турындагы иң соңгы мәгълүматлардан хәбәрдар булырсыз, университет тормышының үзәгендә кайнарсыз.

## КФУның Матбугат үзәге



Матбугат конференциясе, пресс-кит, медиа-план... Бу сүзләр күпләргә, бәлки, теория аша гына таныштыр, ә матбугат үзәгендә исә сез алар белән гамәлдә таныша аласыз. Сезгә студентларның PR-агентлык эшчәнлегендә катнашырга тулы мөмкинлекләр бар. Матбугат үзәге хезмәткәрләре шәһәр, республика газеталары битләрендә, телевизор экраннары, Интернет челтәрләре аша университет абруен күтәрү юнәлешендә эшли, киң җәмәгатьчелек белән элемтәләрне җайга сала, PR-акцияләр оештыра. Мәкалә, пресс-релизлар язарга өйрәнәсегез, эшлекле сөйләшү, әңгәмә кору технологияләренең асылына төшенәсегез килсә, матбугат үзәге нәкъ менә сезнең өчен.

## Татар яшьләренең «DARELFӨNYN» газетасы

«DARELFӨNYN» – университет тормышын, галим-мөгаллимнәр, студентларның уй-фикерләрен туган татар телебездә чагылдырган көзге ул. Яше буенча университет күләмендә барысыннан калышса да, мәгълүмат җәһәтлеге һәм татар телле укучыларны берләштерү ягыннан алда бара. «DARELFӨNYN» газетасы «Ел студенты – 2012» республикакүләм бәйгесендә «Иң яхшы массакүләм матбугат чарасы» номинациясендә төп җиңүче булды. 2013 елда Россиякүләм «МедиаПокорение»фестивалендә «Иң яхшы корпоратив басма» номинациясендә I дәрәҗәле дипломга лаек дип табылды. Ә 2014 елда XVII «Бәллүр каләм - Хрустальное перо» конкурсында «ТРда чыга торган корпоратив һәм махсуслашкан массакүләм мәгълүмат чаралары» номинациясендә җиңүгә иреште. Интернет челтәрендә яңа саннар белән таныша аласыз. kpfu.ru/main_page?p_sub=6451 сылтамасына керү – «DARELFӨNYN»гә эләгү дигән сүз. Редакция вәкилләре сәләтле, язу-сызуга һәвәс яшьләрне бик теләп һәм яратып үз сафларына алырга әзер!

## КФУның «Казанский университет» газетасы

Әлеге газетаны, чын мәгънәсендә, университетның елъязмасы дияргә була. Газетага шулай ук теләгән һәр кеше яза, фикерен белдерә, университет тарихын теркәүгә үз өлешен кертә ала. Атнага ике мәртәбә чыга торган газета белән Интернет челтәрендә kpfu.ru/main_page?p_sub=6212 адресына кереп танышырга да мөмкин. Әгәр университет тарихын язышуда үзегезнең яңа алымнарыгыз, теләгегез бар икән, редакция ишекләре сезнең өчен һәрвакыт ачык. Университетыбыз газетасын бергә гамәлгә кертик.

## «UNIVER TV» телевидениесеннән

сез университет кысаларында уза торган чаралар турында видеомәгълүмат ала аласыз. Телевидение хезмәткәрләре Казан студентлары турында гына түгел, ә бөтен Рәсәй, хәтта дөнья күләмендәге уку йортлары турында сюжетлар әзерли. Һәр көнне «Univer news» мәгълүмати программасы эфирга чыга. Әлеге телепрограмма аша сез кафедра, бүлек, факультет, институтларда һәм, гомумән, университеттаниләр булганын белә аласыз. «Фильмнар, әңгәмәләр» сәхифәсендә университет, укытучылар тормышы тулырак чагылыш таба. Абитуриентлар өчен махсус «Абитуриентка» сәхифәсе бар. Биредә үзегезне кызыксындырган барлык сорауларга җавап таба аласыз. «БДИга әзер бул» сәхифәсендә видеодәресләр урнаштырылган. «UNIVER TV» хезмәткәрләре әзерләгән материаллар ярдәмендә сез имтиханга әзерләнә аласыз. Тапшырулар һәм барлык язмалар kpfu.ru/main_page?p_sub=6211 сайтына урнаштырылган. Телевизион тапшырулар эшләүдә син дә катнаша аласың!

# Вакыйгалар үзәгендә кайна!

Кечкенәдән вакыйгаларның үзәгендә кайнап, башкаларга яңалыкларны иң беренче булып җиткерергә яратасыңмы? Матбугатта язмаларың еш басыламы? Социаль фәннәр, сәясәт белән кызыксынасыңмы? Бу сорауларның берсенә генә булса да уңай җавап биргәнсең икән, димәк, **Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты** Сине көтеп кала!



Биредә бакалаврларга 5 төп юнәлеш буенча белем бирәләр: журналистика (басма матбугат; гаммәви журналистика чаралары ( милли (татар) журналистика); халыкара журналистика; ММЧда яңа компьютер технологияләре), **телевидение**; **реклама һәм җәмәгатьчелек белән элемтә; социология**; **яшьләр белән эшне оештыру**.

Киләчәктә белемле, туры сүзле, ачык фикерле булырдай журналистларны институтның **журналистика бүлегендә** әзерлиләр. Биредә белем алучы студентлар заманча гаммәви технологияләрне төрле яклап өйрәнә. Алай гына да түгел, аларның иң популяр мәгълүмат чараларында: газета-журналларда, радиода, нәшриятларда, интернет басмаларда, мәгълүмат һәм реклама агентлыкларында, матбугат үзәкләрендә практика узу мөмкинлеге бар. Студентларның күпчелеге практика узган урында берегеп, эшләп тә кала. Татар журналистикасы кафедрасы исә милли редакцияләр өчен белгечләр әзерләү белән шөгыльләнә.

Институт базасында әле узган ел гына ачылган **Телетапшыру һәм тележитештерү кафедрасы** – студентларны телевидение белән таныштыра, аның серләренә төшендерә торган зур бер үзәк. Биредә укучы булачак



журналистлар чын мәгънәсендә телевидение эшчәнлегенә чума. Журналистика сәнгатенә өйрәнүдән тыш, алар университетның тәүлек буе эшли торган «UNIVERSMOTRI.RU» каналында операторлык, заманча җиһазлар белән монтаж ясау, көндәлек университет яңалыкларын әзерләү һәм башка телепроектларны тормышка ашыруда катнаша. Боларны исәпкә алганда, студент-тележурналист үз карьерасын беренче курстан ук башлый.

Җәмгыять, анда барган төрле вакыйгалар, бу хактагы уй-фикерләр белән кызыксынасың икән, сине **социология бүлеге** кабул итәргә әзер! Монда белем эстәүче студентлар социаль процессларның төп закончалыкларын өйрәнә, гуманитар һәм социаль фәннәрне тирәнтен үзләштерә, маркетинг һәм реклама хезмәтләренең эшен планлаштырырга өйрәнә, иҗтимагый фикерне һөнәри яктан тикшереп, анализлый белә. Хакимият органнарының аналитика бүлекләрендә, аналитик-социологик үзәкләрдә, реклама хезмәтләрендә, фәнни-тикшеренү үзәкләренең социология лабораториясендә эшлисең, гомумән, социолог һөнәрен үзләштерәсең килсә, рәхим ит!

**Гамәли политология һәм җәмәгатьчелек белән элемтә кафедрасы** исә сәяси аналитиклар, сәяси консалтинг, сәяси багланышлар, сайлаулар технологиясе белгечләрен әзерләп чыгара.

Бакалавриатны тәмамлаган студент белемен һәм һөнәри компетентлылыгын арттыруны магистратурада дәвам иттерә ала.

# Психология? Әллә педагогикамы? Үзең сайла!

**Психология һәм мәгариф институтында** белем алучыларның укулары 4-6 ел белән генә чикләнеп калмый: үзләштергән һөнәрне гомер буе камилләштерергә кирәк булачак. Чөнки тора-бара монда алган белемнәр генә җитми башлый һәм син үзеңнән-үзең тагын да күбрәк белергә, фәнгә бәйле нечкәлекләрне эзләргә тырышачаксың. Бәлкем, шул вакытта нәкъ менә СИН, зур ачыш ясап, тарихка да кереп калырсың! Монда сиңа дөрес юнәлеш, кирәкле мәгълүмат бирәчәкләр – ә калганы үз кулларыңда!

Педагогиканы яратучылар күп гасырлардан килгән бай тәҗрибә белән танышып, алга таба үзләре мәктәп укучыларын фән серләренә төшендерә алачак. Андый кешеләр күңелләре белән мәңге яшь булып калалар!

Әгәр син психология юнәлешен сайлагансың икән, бик тиздән үз-үзең һәм әйләнә-тирә белән гармониягә керү юлларын, аерым кешеләрнең психологик үзенчәлекләрен аерып карый алачаксың. «Яхшы психолог» дигән исем үзе генә ни тора бит!



Психология һәм мәгариф институты Януш Корчак халыкара җәмгыяте, Кытай университетлары һ.б. арасында ныклы хезмәттәшлек җепләре ялгаган һәм биредә күпсанлы халыкара семинар, конференцияләр, төрледән-төрле кызыклы чаралар уздырыла. Аларда син дә катнашып, яңа ачышлар, зур уңышларга ирешә алачаксың! Димәк, алга!

# Киләчәгеңне бүген төзе!

Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты узган елның ноябреннән яңа форматта эшли башлады. Ул – уку йортыбызның иң зур институтларының берсе. Ул Балалар университетларының Европа ассоциациясе (Вена, Австрия), Мәктәп дәреслекләрен өйрәнү буенча халыкара ассоциация (Аугсбург, Германия) составында исәпләнә. Даны еракларга таралган институтта Сине дә көтәләр!

**«Тарих институты»** бүлегендә сине тарихның бөтен нечкәлекләре белән танышу, төрки халыклар, Идел һәм Урал буе, чит ил тарихын өйрәнү көтә.

**Халыкара мөнәсәбәтләр бүлеген** тәмамлаган белгечләр рәхәтләнеп хокук проектлары кабул итүдә, эчке сәяси курсларны тормышка ашыруда катнаша алачак. **«Көнчыгышны өйрәнү институты» бүлеге, Тәрҗемә белеме һәм бөтендөнья мәдәни мирас бүлекләрендә** син шулай ук төпле белем һәм ныклы тәрбия алачаксың.

Син лекцияләр тыңлау, семинарларда катнашу, контроль биремнәр башкару белән генә чикләнмичә, рәхәтләнеп чын тарихи дөньяга чумарсың. Бәлки, нәкъ менә син югалган цивилизация серләрен ачарсың, борынгы культураларны, укытучы булу нечкәлекләрен өйрәнерсең. Шулай ук Көнчыгыш, Азия һәм Африка телләре, тарихы, икътисады, сәясәте белән танышырсың. Синең өчен лекцияләрне хәтта АКШның Индиана, Радгерс, Огайо институтларыннан килгән профессорлар укыячак. Институт бик күп чит ил университетлары белән хезмәттәшлек итә. Димәк, син Бөекбритания, Германия, Төркия, Польша, Казахстан һәм башка илләрдә стажировка үтә яисә җәйге мәктәпләрдә белеменне арттыра алачаксың.



Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты үзенең археологик һәм этнографик музейлары белән дә дан тота.

Бу институтта чит телләрне өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Монда синә инглиз, алман, француз, испан, кытай, төрек, гарәп, корея, фарсы, суахили, африкаанс, латин һәм борынгы грек телләрен үзләштерә алу мөмкинлеге бар.

Институтта тарих һәм археология, көнчыгышны өйрәнү һәм африканистика, халыкара мөнәсәбәтләр, чит ил регионоведениесе, лингвистика, антропология һәм этнология, культурология, сәнгать тарихы, музей фәнен өйрәнү, мәдәни һәм тарихи мирас объектларын саклау, педагогик белем бирү юнәлешләре буенча бакалавр һәм белгечләр әзерлиләр. Үзләренең тормышларын фән белән бәйләргә теләүчеләр халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм археология, антропология һәм этнология, педагогик белем бирү, сәнгать тарихы юнәлешләре буенча магистратурада укуларын дәвам итә алачаклар.





## Халыкара хезмәттәшлек

**КФУ дөньяның 35 иленнән 90нан артык югары уку йорты һәм фәнни үзәк белән хезмәттәшлек итә:**

- РИКЕН институты, Япония
- Юстус Либих университеты, Германия
  Макс Планк институты, Германия
- Хунань педагогика университеты, Кытай
- INALCO Көнчыгыш телләр һәм цивилизацияләр милли институты, Франция
- Хельсинки университеты, Финляндия
- Лювена Католик университеты, Бельгия
- Стамбул университеты, Төркия
- Гранад университеты, Испания
- Фрибург университеты, Швейцария
- Джеймс Мэдисон университеты, АКШ
  Төньяк Каролина штаты университеты, АКШ

# Син дә химик элемент ач!

Химия фәне һәм химик белем бирүнең Россия һәм дөнья күләмендә иң олы һәм авторитетлы үзәге - **А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты**.

Бу институтны Казан университеты тарихыннан аерып карап булмый. Чөнки уку йорты ачылган 1804 елда ук, Университет Уставы нигезендә, физика һәм математика фәннәре факультеты базасында химия кафедрасын ачу турында фикерләр карала башлый. Бик күп галимнәр бөтен дөньяга билгеле Казан химия мәктәбенә нигез сала. 1929 елда исә әлеге юнәлеш институт статусын ала.

Бүгенге көндә институт югары уку йорты лабораторияләренә, академик һәм фәнни-тикшеренү институтларында, завод лабораторияләренә, мәктәп-гимназияләрдә эшләү өчен, белгечләр әзерли. Шулай ук экология белгечләре әзерләүгә аерым игътибар бирелә. Хисаплау техникасы белән эшләүгә әзерлек тә даими башкарыла. Әгәр син әлеге институтка укырга керсән, хокук буенча белем туплый, менеджмент нигезләре һәм этикасы белән таныша, тирәнтен рәвештә чит телләр өйрәнә башлаячаксың.



Биредә химиянең төрле өлкәләренә: органик булмаган, органик, аналитик, элементоорганик, физик, электрохимия һәм координацион кушылулар химиясенә караган белгечләр әзерлиләр. Соңгы елларда нанохимия һәм наноматериаллар, химик промышленность өчен нәтиҗәле катализаторлар, яңа дару препаратларын әзерләү өлкәсе буенча да белем бирелә һәм фәнни тикшеренүләр алып барыла.

Химия институтында «Хемоинформатика һәм молекуляр модельләштерү» юнәлеше буенча КФУ һәм Страсбург I университетларының Халыкара икеләтә диплом программасы гамәлдә.

Бутлеровның фәнни эшчәнлеген дәвам итәсең, әлеге кызыклы һәм мавыктыргыч фән белән дуслашасың килсә, Химия институтына рәхим ит! Кем белә, бәлки, берәр химик элемент та ачып куюың бар! Институтны тәмамлаганнар Россиядә генә түгел, АКШ, Япония, Канада, Германия, Корея, Израиль һәм башка илләрнең танылган уку йортларында алдынгы белгеч һәм профессор исемнәрен йөртә.



# Җир астындагы серле дөньяга рәхим ит!

Безнең планетадан кызыграк һәм серлерәк тагын нинди планета бар икән? Тиздән кояш системасы буенча күршеләребез Марс белән Айда да файдалы казылмалар эзли башлаячаклар дигән сүзләр йөри. Син хыялый, һәм син сәяхәт итәргә, ачышлар ясарга яратасың бит? Димәк, сине **Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институтында** колач җәеп каршы алачаклар.







Күрәк белән җир казулар артта калды. Хәзер әлеге институтны тәмамлаучылар геомәгълүмати технологияләрдән файдалана һәм заманча җиһазлар белән эшли белә. Бәлки, нәкъ менә СИН җир астында кара алтын таба торган заводны җитәкләрсен! Ышанмыйсыңмы? Бу бары тик вакыт эше генә.

Биредә **«кара алтын-газ эше»** һәм **«геология»** юнәлешләре буенча кабул итәләр. Соңгысы тагын берничә профильгә бүленә: **«геология», «геофизика», «геология һәм кайнар казылмалар геохимиясе», «гидрогеология һәм инженерлык геологиясе»**. Уку университет һәм институт дәрәҗәсендәге кызыклы чаралар, конференция-семинарлар белән үрелеп бара. Студентларның Россиядән генә түгел, ә Азия, Африка һәм Латин Америкасы илләреннән икәнен исәпкә алсак, синең дусларыңның географиясе бик киң булачак.

Әлеге интситутны тәмамлаган студентларны, һичшиксез, яхшы эш һәм хезмәт баскычы буенча үсеш көтә. Алар **«Лукойл», «Роснефть», «Татнефть», «Газпром», «Schlumberger»** кебек нефть, геологик һәм геофизик эре компанияләрдә, министрлыкларда, фәнни-тикшеренү, экологик һәм белем бирү оешмаларында эшли ала.

Һөнәр сайлаганда, шуны истә тот: геолог кына Җирнең үткәненә, әйтик, динозаврлар эпохасына «сәяхәт итә» һәм шул ук вакытта заманча технологияләр ярдәмендә тикшеренүләр үткәрә ала.

# Үзеңнең машина төзисең киләме?

**Инженерия институтына** рәхим ит! Ул КФУның укыту-фәнни бүлекчәсе санала.

Биредә инженер-техник кадрлар һәм белгечләр әзерләнә. Шулай ук вуздан соңгы һөнәри белем бирү, инженерия һәм технология өлкәсендә эшчеләрнең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү гамәлгә ашырыла, фундаменталь һәм гамәли фәнни тикшеренүләр алып барыла.

2013 елдан Инженерия институтында Сыйфат белән идарә итү, Биомедицина инженериясе һәм инновацияләр белән идарә кафедралары эшләп килә. Биоинженерия һәм тормыш куркынычсызлыгы, Прототиплаштыру, Конструкцион материалларны табу һәм эшкәртү технологияләре,Полимерэшләнмәләрен ясау технологияләре, Тешләр протезлауның прецизион технологияләр үзәге фәнни лабораторияләре уңышлы гына эшләп килә.



2014 елда институтта **«Сыйфат белән идарә итү»** юнәлеше буенча бакалавриат; **«Инноватика: Интеллектуаль милек белән идарә итү», «Биотехник системалар һәм технологияләр», «Инноватика: Югары технологияләр өлкәсендә эшмәкәрлек»** юнәлешләре буенча магистратурага кабул итәләр.



**Инженерлык белемен бирүдә приоритет юнәлешләр:**

- медик-биологик приборлар ясау;
- машина төзү (автомобиль төзү);
- нанотехнологияләр һәм микросистемалы җиһазлар;
- мәгълүмати-коммуникацион системалар һәм җиһазлар;
- радиофизик системалар һәм җиһазлар;
- нефть-газ эше;
- әйләнә-тирә мохитне саклау;
- гидрогеология һәм инженер геологиясе.



# Табиб та, биолог та!

Ил күләмендә алдынгы юнәлешләрне куәтләү максатыннан, Казан федераль университетында яңа проектлар, идеяләр тормышка ашырыла. Медицина һәм биологик технологияләр аеруча алга киткән өлкәләрдән санала. Хәзерге көндә 2013 елда ачылган **Фундаменталь медицина һәм биология институтының** максаты - фундаменталь тикшеренүләргә нигезләнеп, заманча дөньяви стандартларга туры килә торган биология һәм медицина белеме бирү.



Татарстанда медицина фәненең алга китешенә КФУда әзерләнгән белгечләр зур йогынты ясаячак. Алар **яңа буын табиблары** булачак. Ә уку йортының, югары квалификацияле белгечләр әзерләү өчен, бөтен мөмкинлекләре дә бар. **Әлеге институт күп төрле белгечләр: табиблар, стоматологлар, табиб-генетиклар, табиб-рентгенологлар һ.б. әзерләүне максат итеп куя.** Шулай ук Россиянең 200дән артык медицина оешмаларында, дөньяның иң яхшы фәнни үзәкләрендә стажировка үтү мөмкинлеге дә бар. Сәламәтлек саклау өлкәсендә белгечләр әзерләү һәм югары сыйфатлы уку процессы өчен күп профильле клиника булдыру зарур. КФУ студентлары өчен моңгый мәйдан булып **2 номерлы Республика клиник хастаханәсе** хезмәт итә. Күптән түгел РКБ-2 базасында заманча җиһазлар белән тәэмин ителгән трансляцион медицина үзәге эшли башлады.

Шулай ук **«ФАРМА 2020»** программасын тормышка ашыру кысаларында **фармацевтика буенча фәнни-белем бирү үзәге дә** ачылды. Биредә инновацион дарулар һәм субстанцияләр эшләп чыгару белән шөгыльләнәләр. Бу процесска химия, биология, медицина һәм фарматехнология буенча белгечләр җәлеп ителде.

Фундаменталь медицина һәм биология институтын тәмамлаган белгечләр хезмәт базарының төрле өлкәләрендә үз урыннарын таба. Алар алган белемнәрен медицина, биотехнология һәм азык-төлек җитештерү, нефтехимия сәнәгате, табигатьне саклау оешмаларында, Эчке эшләр министрлыгының криминалистика бүлекләрендә, ландшафт дизайны фирмаларында куллана алачак. Киләчәктә бөек галимнәр әзерләүгә көчләрен сынап карарга теләүчеләр өчен, институтта педагогик белем бирү дә каралган.

# Син дә Лобачевский «оныгы» бул!



Саннар төшенә керер үәдәтәме? Син дә аларны үәдәт! **Н.И.Лобачевский исемендәге математика һәм механика институтында,** математика һәм механика өлкәләрендә заманча хисаплау системаларын кулланып, фундаменталь әзерлек алып барыла. Монда логик иҗади фикерләүгә, заманча математик методларны, катлаулы мәсьәләләр чишү өчен программа белән тәэмин итү эшен үзләштерергә һәм кулланырга өйрәтәләр. Институт студентлары персональ компьютер белән эшләүдә төпле белем һәм тәҗрибә ала. Талантлы яшьләрне фундаменталь фәнни-гамәли тикшеренү эшләренә кызыксындыру уяту максатыннан, институт даими рәвештә төрле Россия, халыкара масштабта конференцияләр оештыра. Шундыйларның берсе – «Лобачевский укулары» мәктәп-конференциясе. Институт хезмәткәрләре, аспирантлар һәм студентлар үзләренең фәнни эшләре, нәтиҗәләрен «LobachevskiiJournalofMathematics» электрон журналында бастыру мөмкинлегенә ия. Шулай ук студентлар Россиянең һәм чит илләрнең иң алдынгы фәнни-белем бирү үзәкләрендә стажировка үтә ала.

**Иниситутның юнәлешләре:**

- Математика
- Математика һәм компьютер фәннәре
- Гамәли математика
- Механика һәм математик модельләштерү
- Гамәли механика
- Педагогик белем бирү

**Педагогик белем бирү юнәлешенең 3 профиле бар:**

- Математик белем бирү, информатика һәм IT-технологияләр;
- Математика, информатика һәм IT-технологияләр билингваль татарча-русча мохиттә (бу юнәлеш буенча татар төркемнәре оеша һәм уку рус һәм татар телләрендә алып барыла);
- Математика һәм инглиз теле.


# ИТИСтан зур уңышка!



**Мәгълүмати технологияләр һәм системалар югары мәктәбе** – КФУның иң заманча бүлекләренең берсе, уникаль проект. Төбәкнең эре IT-компанияләре, шулай ук Microsoft, HP, Cisco, Oracle брендлары республикабызда IT-белгечләр әзерләүгә алынды.

Биредә укырга теләүчеләр Россиянең һәм дөньяның алдынгы IT-компанияләре белән бергә әзерләнгән программа буенча белем алачак. Лекцияләрне КФУның танылган галимнәре, чит ил уку йортларыннан чакырылган белгечләр укый. ИТИСта **Microsoft, HP инновацион үзәкләре, Cisco укыту лабораториясе, Fujitsu, Samsung, Барс-груп, SmartHead, JetBrains** кебек компанияләрнең лабораторияләре бар. Аларда студентлар компанияләрнең алдынгы белгечләре ярдәмендә реаль проектларны тормышка ашыра, программалы тәэмин итү, веб-сервислар, мобиль приложениеләр уйлап таба. Шуна күрә студентлар укыган вакытта ук иң яхшы IT-компанияләрдә эшли башлый. Аларның уңышлары моның белән генә чикләнми. Яндекс, Google, Mail.ru компанияләре уздыра торган конкурсларда да студентлар зур җиңүләр яулый. Шулай ук халыкара студент проектларын тормышка ашыруда актив катнаша, нәтиҗәдә, башка илләрдән дуслар табу мөмкинлеге арта.

ИТИСка авырлыклардан курыкмаган, катлаулы мәсьәләләрне чишәргә яраткан, үз-үзенә ышанычы нык булган һәм зур уңышларга ирешергә теләгән укучылар кирә. Әгәр син үзеңне шундый дип уйласаң, рәхим ит! Синең өчен ишекләр һәрвакыт ачык!



# Кисәкчектән галәмгә кадәр!

**Физика** – табигатьне аңлау фәне. Әгәр синең дә бу авыр фәннең асылына төшенәсең килсә, бирегә рәхим ит! Монда син физик күренешләрне төрле дәрәҗәдә: гади элементлардан алып, бөтен галәмгә кадәр өйрәнә алачаксың.

**Бүгенге көндә Физика институты ул:**

- физика фәннәре буенча Россиянең әйдәп бара торган уку-укыту һәм фәнни үзәге;
- 180 укытучы, шуларның 57се – профессор;
- 16 кафедра;
- 3 кафедраара белем бирү-фәнни үзәкләре;
- 30дан артык махсуслаштырылган фәнни һәм 150дән артык уку лабораторияләре;
- инженерлык белгечлеге белән берррәттән, классик тирән нигезле белем бирү;
- заманча, нәтиҗәле укыту формалары;
- КФУның абруйлы дипломы;
- киң белгечлек өлкәләре буенча әзерлек;
- теория һәм экспериментның ярашуы;
- Россиядә һәм чит илдә яхшы эшкә урнашу мөмкинлеге.



Институт составында **4 бүлек бар:** астрофизика һәм космик геодезия; физика; радиофизика һәм телекоммуникация; фәнни-педагогик. Монда син физика, математика, информатика, хәзерге заман инженериясе нигезләрен төптән өйрәнәчәксең. Шулай булгач, син һәрбер өлкәдә дә эшли алачаксын дигән сүз! Уку җиңел булмаса да, Физика институты диварлары арасында үткәрелгән студент еллары беркайчан да онытылмаячак!



Физика институты составындагы В.П.Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясе базасындагы **Планетарий**. Монда син туган җиребездә басып торган килеш, космос, аның һәр детале белән таныша алачаксың.



**Академик Парин урамында урнашкан «авыл» бер дә гади түгел. 2013 елда Казаныбызда узган XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада ярышлары чорында биредә 170тән артык илдән килгән 13500 спортчы һәм тренер яшәде.**

# Авылдан «авылга» кил!

Заманча «авыл»ның гомуми яшәү мәйданы – 274000 м2 (һәр кешегә 25 м2 туры килә). Йортларның эче бик матур, якты, кондиционерлар бар, җиһазлар яңа, пластик тәрәзәләр тавыш үткәрми, лифт эшли. Бүлмәләрдә 2-3 кеше яши. Һәркайсында душ бар. Аш бүлмәсе 3-4 бүлмәгә бер туры килә. Интернетка керү өчен мөмкинлекләр каралган. Куркынычсызлык өчен дә борчылыр урын юк: коридорлар видеокамера белән тәэмин ителгән. Тулай торак билгеле бер вакытта бикләнә. 11 дән 6 га кадәр шаулап йөрергә ярамый!

Бассейнга, тренажёр залларына йөрергә, кыш көне тимераякта шуарга (ишегалдында), ә җәй көне велосипедта, роликларда йөрергә (кулланып торырга бирәләр), теннис, футбол уйнарга була. Һәр бәйрәм саен, төрле кичәләр, психолог, мәртәбәле куналар белән очрашулар, дискотекалар үткәрелә.

## Супермаркет



Студентларга көнкүреш кирәк-яраклары, азык-төлек товарлары сатып алу өчен, әллә кая барып йөрисе юк. Универсиада авылы территориясендә ачылган супермаркетта бөтен әйбер бар! Бәяләре дә



кыйммәт түгел. Ә элмә такталарда товар исемнәре өч телдә: рус, татар һәм инглиз телләрендә язылган.

## Медицина үзәге



Хәзер студентларга, сәламәтлекләрен тикшерү өчен, ерак барасы юк. Универсиада авылында Медицина үзәге ачылды. Экспертлар аның эшчәнлеген чит илләрнекеннән дә югарырак бәяли. Регистрация ике инфомат белән җиһазландырылган: алар ярдәмендә, табибка күренү өчен, электрон чиратка язылырга,



белгечләр турында тулы мәгълүмат алырга мөмкин.

Үзәктә тикшеренү узар өчен, төрле методлар кулланыла. Заманча җиһазландырылган эндоскопия, флюорография, терапия, УЗИ, рентген, хирургия һәм травматология кабинетлары бар. Шулай ук көндезге стационар, физиотерапия, нурлы диагностика бүлекләре эшли. Һәркайсының эш графигы пациент таләпләрен исәпкә алып төзелгән.

## Матурлык салоны



Казан федераль университеты студентлары һәрьяктан камил булырга тиеш. Матурлык һәм пөхтәлек ягыннан бигрәк тә. Ә Универсиада авылында яшәүчеләр хәзер үз матурлык салонына йөри. Вуз җитәкчелеге алар өчен Яңа елга зур бүләк ясады. Матурлык салонында



чәчтарашханә хезмәтләре күрсәтелә. Заллар, традицион рәвештә, икегә бүленгән: егетләр һәм кызлар өчен. Һәркайсында икешәр урын бар. Салонда шулай ук массаж кабинеты бар, косметологик хезмәтләр күрсәтелә, тырнак сервисы һәм солярий эшли.

## Даруханә



Универсиада авылында 24 сәгать буе эшли торган даруханә бар. Бирегә чит илдә һәм Татарстанда җитештерелгән даруларны алырга мөмкин.

## Автомәктәп



КФУ студентлары «B» категорияле машина йөртү таныклыгы да алып чыга ала, чөнки «авыл»да автомәктәп ачылды. Машина йөртергә өйрәнү өчен, мәктәптә ватан һәм чит ил автомобильләре булган автопарк бар.

# Спорт сөючеләр өчен







**Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты** ишекләре спорт сөючеләр өчен һәрвакыт ачык. Институтны тәмамлаган студентлар физик тәрбия һәм тормыш иминлеге укытучысы, спорт белгече булып чыга. Шулай ук биологик белем (физиологик аспектта) бирелә.

Бинада гомуми һәм индивидуаль дәресләр өчен аудиторияләр бар. Практиканы студентлар урта гомуми белем бирү учреждениеләрендә, балалар һәм яшьләр өчен урта мәктәпләрдә, «Динамо», «Рубин», «Зенит» кебек спорт оешмаларында үтә.

I һәм II курс студентлары өчен «Яльчик» укыту-сәламәтләндерү үзәгендә дәресләр уздырыла.

Студент елларында ук зур үрләр яулап, ил күләмендә танылу турында кем генә хыялланмый икән?! КФУда спортка, сәламәт яшәү рәвешенә игътибар аеруча зур. Ә Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институтын тәмамлаучыларның күбесе, диплом алганда, Татарстан, Россия, хәтта дөнья чемпионы дәрәҗәсенә ия була.

Гомумән, республикабызда спортка зур игътибар бирелә. Яшь буынны рухи яктан гына түгел, ә тән ягыннан да сәламәт итеп тәрбияләү өчен, җитәкчелек бик күп мөмкинлекләр тудыра. Казан федераль университеты базасында гына да 11 спорт объекты бар. Укудан буш вакытны заманча тренажерлар белән җиһазландырылган залларда шөгыльләнеп, физик халәтенне ныгытырга, яңа үрләр яуларга мөмкин. Аларда студентлар өчен ташламалар каралган. Кайберләрендә хәтта бушка шөгыльләнергә мөмкин.

# Бу исемлекнең дәвамчысы – син!



**Гариф Ахунов** - прозаик, драматург, публицист һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе *(Татар филологиясе бүлеге)*



**Нурихан Фәттах** - Татарстанның халык язучысы *(Татар филологиясе бүлеге)*



**Аяз Гыйләҗев** - Татарстанның халык язучысы *(Татар филологиясе бүлеге)*



**Хатыйп Госман** - язучы, әдәбият галиме, педагог *(Татар филологиясе бүлеге)*



**Илдар Юзеев** - Татарстанның халык шагыйре *(Татар филологиясе бүлеге)*



**Мирфатих Зәкиев** – филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы *(Татар филологиясе бүлеге)*



**Миңназыйм Сәфәров** - «Ватаным Татарстан» газетасы баш мөхәррире *(Журналистика бүлеге)*



**Римма Ратникова** - ТРның Дәүләт Советы рәисе урынбасары, Журналистлар берлеге рәисе *(Журналистика бүлеге)*



**Ренат Харис** - ТРның халык шагыйре, М.Җәлил һәм Г.Тукай ис. премияләре лауреаты *(Рус филологиясе бүлеге)*



**Рәгъде Халитов** - РФ һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе *(Сәнгать бүлеге)*



**Илшат Әминов** - «Татарстан - Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясенең генераль директоры *(Журналистика бүлеге)*



**Дамир Натфуллин** - Татарстан мәдәният министрлыгының музей программалары һәм мәдәни туризм бүлеге мөдире *(Психология һәм мәгариф институты)*



**Айдар Фәйзрахманов** - Татар Дәүләт опера һәм балет театры солисты, ТРның Дәүләт фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе, ТРның халык һәм РФның атказанган артисты *(Сәнгать бүлеге)*

## Мәктәп укучылары – студентлар?

### IT ЛИЦЕЙ-ИНТЕРНАТ



IT лицей-интернат – КФУ базасында сәләтле балалар өчен оештырылган структур үзәк. Монда республиканың төрле районнарыннан һәм Идел буе округыннан килгән балалар укый.

Лицей барлыгы 360 укучыга исәпләнгән. Укучылар 7 сыйныфка кабул ителеп 11нче сыйныфка кадәр белем алачаклар. Беренче чыгарылыш 2017 елда булыр дип көтелә.

### Н.И.ЛОБАЧЕВСКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ЛИЦЕЙ-ИНТЕРНАТ



2013/2014 уку елыннан КФУ составына кергән Н.И.Лобачевский исемендәге лицей-интернат – Россиянең иң яхшы 25 мәктәбе рәтендә. Ул югары уку йортының сәләтле балалар белән эшләү мәйданчыгы булып тора. Лицейда Россиянең булачак лидерларын тәрбиялиләр, һәркем берьюлы берничә проектта катнашып, иҗади сәләтен үстерә, КФУ галимнәре белән берлектә фәнни тикшеренүләр үткәрә, «ЛиГа» лицей газетасында һәм «ЛиСт» телестудиясендә журналистлык күнекмәләрен арттыра ала.

### КЕЧЕ УНИВЕРСИТЕТ




Кече университет – вузга кадәр белем бирү үзәге. Аның максаты: балаларның иҗади һәм эзләнү эшчәнлеген үстерү. Ел саен университетның 7 бүлегендә барлыгы 500гә якын бала белем ала. Укыту программасына лекцияләр, практик дәресләр, тренинглар һәм консультацияләр кертелгән. Олимпиадаларга әзерләнү һәм эзләнү төркемнәре эшли. Укучыларга Н.И.Лобачевский исемендәге китапханәгә йөрергә мөмкинлек бирелә.

### БАЛАЛАР УНИВЕРСИТЕТЫ



КФУның Балалар университеты эшчәнлеген 2011 елның октябрь аенда башлап җибәрде. Бу проект 8 яшьтән алып 12 яшькәчә балалар өчен каралган. Өйдә әти-әниләр аңлатып бирә алмаган һәм мәктәптә дә ачыклык кертелмәгән сорауларга җавапларны укытучылар үзенчәлекле лекцияләр аша балаларга җиткерә. Мәсәлән, «Йолдызлар нигә атыла?», «Кешеләр нигә ярлылар һәм байларга бүленә?», «Йоклаганда нигә төш күрәбез?» һ.б.

# Кем мин?



**Абитуриент** – безнеңчә итеп әйткәндә, ул югары уку йортына керергә әзерләнүче егет һәм кызлар. Латинчадан исә «abiturus» яки «abiturientis» – «китәргә», «бетерергә» мәгънәсендә, ягъни башка җиргә укырга кермәүче мәктәпне тәмамлаган югары сыйныф укучысы күздә тотыла. Студентлыкка кандидат дигән кебек, «абитуриент» сүзе СССРда 50нче елларда кулланыла башлый һәм бүген дә без аның мәгънәсен нәкъ шулай кабул итәбез.

**Белгеч** – студент тарафыннан махсус укыту программасы үзләштерелгән квалификация. Россиядә белгечләр 5 ел әзерләнә. Квалификация Дәүләт аттестацион комиссиясендә якланган диплом проекты яки диплом эше нәтиҗәләренә карап бирелә һәм магистратура яисә аспирантурага керү мөмкинлеге туа. Киләчәктә «белгеч» дигән квалификацион дәрәҗә юкка чыгачак, чөнки югары белем алуга бәйле законда яңа дәрәҗәләр барлыкка килде.

**Бакалавр** – югары белемнең укыту программаларын үзләштергән кешеләргә бирелә торган академик дәрәҗә яки квалификация. Болонья процессында катнашучы илләр өчен тәмамланган югары һөнәри белем буларак санала. Бакалавр дипломы югары белем таләп ителә торган урынга эшкә урнашканда кулланыла ала һәм магистратурада укуны дәвам иттерү мөмкинлеге бирә. Россиядә бу дәрәҗә 1996 елда кертелде. Белем алу срогы 4 елдан да ким түгел.

**Магистр** – студентка магистратураны тәмамлагач бирелә торган академик дәрәҗә яки квалификация. Магистратура – бакалавриаттан соң килә торган югары һөнәри белем баскычы. Күп кенә алдынгы илләрдә магистр дипломы иң яхшы дипломнардан санала, бер уку йортыннан икенчесенә күчү мөмкинлеге бирә. Магистр программасын үзләштерү вакыты (көндезге бүлектә) – 2 ел. Магистрга, диссертациясен яклагач, аспирантурага керү мөмкинлеге бирелә.

**Аспирант** – аспирантурада укып, билгеле бер өлкә буенча фән белән шөгыльләнүче югары белемле студент. 3 ел дәвамында (көндезге бүлектә) махсус программаны үзләштергәннән соң, «аспирант» дәрәҗәсе бирелә. Сайлап алынган юнәлеш буенча ул фәнни-тикшеренү эше алып бара. Фәнни хезмәтен Югары аттестацион комиссия раслаган советта яклаганнан соң, аңа фән кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә бирелә.

Шуны исеңдә калдыр, дустым: югары уку йортына кергәч, син горур рәвештә СТУДЕНТ исемен йөртәчәксең! КФУ СТУДЕНТЫ исемен!!! Аны лаеклы рәвештә аклау өчен, шактый тырышырга туры киләчәк. Юкка гына уку – энә белән кое казу димәгәннәр. Энәнең юан саплы, коеның бик тирән булуын телибез!

Схема 1.
КФУ филиаллары




**Алабуга институты**
*ТР Алабуга ш., Казан ур., 89*
kpfu.ru/main_page?p_sub=6207

**Чистай филиалы**
*ТР, Чистай ш. Студентлар,ур. д.15*
filinch.ru

**Яр Чаллы институты**
*Яр Чаллы ш., Тынычлык пр., 68/19*
kpfu.ru/main_page?p_sub=6206

Схема 2.
Казан шәһәрендә КФУ төп биналарының урнашу тәртибе

ИТИС югары мәктәбе, КФУның Медиа-Үзәге *Проф.Нужин ур., 1/37*

КФУ ның төп бинасы, *Кремль ур., 18*

Фундаменталь медицина һәм биология институты, Юридик факультет

А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты, *Лобачевский ур., 1/29*

II корпус *Кремль ур., 35*
Кабул итү комиссиясе,
Экология һәм география институты,
Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты,
Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты, 2 корпус
*Кремль ур., 35*

Идарә һәм территориаль үсеш институты *К.Маркс ур., 73*

УНИКС мәдәни-спорт комплексы *Проф.Нужин ур., 2*

Фундаменталь медицина һәм биология институты, *К.Маркс ур., 74*

Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты *Товарищеская ур., 5*

Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты, *Кремль ур., 4/5*

Идарә һәм территориаль үсеш институты, *Кремль ур., 6/20*

Физика институты *Кремль ур., 16*

Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты, *Сул Болак ур., 44*

Психология һәм мәгариф институты, *Межлаук ур., 1*

Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты *Межлаук ур., 3/45*

«Мәскәү» спорткомплексы, *Мәскәү ур., 49*

Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты, *Пушкин ур., 1/55*

Фәлсәфә факультеты, *Пушкин ур., 1/55*

Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты, *Татарстан ур., 2*

Икътисад һәм финанс институты, *Бутлеров ур., 4*

**Инженерия институты** *ул. Сайдашева, 12*

«Бустан» спорткомплексы, «Бустан» бассейны, *Кулагин ур., 8а*

Универсиада авылы, «Буревестник» бассейны, Теннис академиясе




Универсиада авылына бару схемасы (8 нче номерлы троллейбус маршруты)

Казан федераль университеты
«DARELFӨNYN» газетасының махсус чыгарылышы

Мөхәррир – Илдар Азат улы Кәримов
Иҗат коллективы: Д.Р.Миннекаева, А.Ю.Садыйкова, Л.Х.Исхакова
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева
Фотохәбәрчеләр: В.Михневский, А.Сатонина, А.Галимуллина, Ә.Фазлыйәхмәтов, С.Тябин, Р.Газизов, Ю.Карпова
Газета бушлай таратыла
Тираж 1000

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00. «Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.